**Татарстан Республикасы**
**Арча муниципаль районы**
**Арча муниципаль берәмлеге**
**Арча шәһәр Советы**
**422000, Арча шәһәре, Советы мәйданы, 27**
**тел. 3-15-25, 3-16-25**

**Татарстан Республикасы**
**Арча муниципаль районы**
**Арча шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Арча шәһәр Советы**
**422000, Арча ш., Совет мәйданы, 27**
**тел. 3-15-25, 3-16-25**

---

**Арча шәһәр Советы**
**КАРАРЫ**

28 сентябрь 2021 ел № 48

**«Россия Федерациясе дәүләт урман фонды җиренә һәм физик һәм юридик затларның шәхси милкендәге җирләргә кермәгән яшел үсентеләрне кисү тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Арча шәһәр Советының 2021 елның 18 февралендәге 29 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Урман кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Әйләнә-тирә мохитне саклау турында» 2002 елның 10 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы Федераль закон, «Арча шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, «Арча шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендәге Россия Федерациясе дәүләт урман фонды җиренә һәм физик һәм юридик затларның шәхси милкендәге җирләргә кермәгән яшел үсентеләрдән рациональ файдалану, саклау һәм яңадан үстерү максатыннан, Арча муниципаль районы Арча шәһәр Советы карар бирде:

1. «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Арча шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә Россия Федерациясе дәүләт урман фонды җирләренә һәм физик һәм юридик затларның шәхси милкендәге җирләргә кермәгән яшел үсентеләрне кисү тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Арча шәһәр Советының 2021 елның 18 февралендәге 29 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Арча шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә Россия Федерациясе дәүләт урман фонды җирләренә һәм физик һәм юридик затларның шәхси милкендәге җирләргә кермәгән яшел үсентеләрне кисү тәртибе турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертергә һәм аны кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында җирлекләр бүлегендә урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Арча шәһәр башкарма комитетына йөкләргә.

«Арча шәһәре» муниципаль берәмлеге башлыгы,
Арча шәһәр Советы рәисе И.Г. Нуриев